ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 67 от «10» 03 2022 г.

Шәһәр һәм район территорияләрен чистарту
буенча санитар- экологик ике айлык
игълан итү турында

Санитар-эпидемиологик һәм экологик хәлне яхшырту, кеше саулыгына әйләнә-тирә мохитнең зарарлы һәм куркыныч факторлары йогынтысы дәрәҗәсен киметү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендә кабул ителгән б-392 нче номерлы боерыгын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. 2022 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр шәһәр һәм район торак пунктлары территорияләрен чистарту буенча санитария-экология ике айлыгын игълан итәргә.

2. Мамадыш муниципаль районы авыл җирлекләре һәм Мамадыш шәһәре башкарма комитеты җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- ведомство карамагындагы территорияләрнең санитар-экологик хәлен яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар планын эшләргә һәм 20 мартка кадәр расларга;

- ике айлык үткәрү эшләрен координацияләү өчен оператив штаблар төзергә;

- авыл җирлекләре һәм Мамадыш шәһәре территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләре, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләре үтәлешен тикшерүдә тотуны көчәйтү өлешендә җирле үзидарә органнарының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары эшен активлаштырырга;

- су объектларының су саклау зоналарын, пляжларны, скверларны, паркларны, балалар мәйданчыкларын, азык-төлек һәм әйбер базарларын, халык күпләп ял итә торган урыннарны, зиратларны, шәхси торак сектор территорияләрен, ташландык биналар, тузган төзелешләрне һәм корылмаларны санитар чистарту, аларны дератизацион эшкәртү, автомобиль юлларының юл буе полосалары, контейнер мәйданчыкларын төзү һәм ремонтлау буенча чаралар үткәрергә;

- каты көнкүреш һәм биологик калдыклар (үләт базлары) полигоннарын тиешенчә карап тотуны һәм эксплуатацияләүне тәэмин итү һәм алар янындагы урыннарны санитар чистарту буенча чаралар күрергә;

- терлекчелек комплекслары калдыкларын рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү буенча чаралар күрергә;

- «Татарстан Республикасы Экологик картасы» геомәгълүмат системасы

http://ecokarta.tatar.ru/ ярдәмендә ведомство буйсынуындагы территориядә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү мониторингын, шул исәптән «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы, «Мәктәп экопатруле» мобиль кушымтасы чаралары буенча кергән хәбәрләрне дә исәпкә алып, гамәлгә ашырырга;

- Мамадыш муниципаль районының административ комиссиясенә һәм Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә шәһәр һәм район территорияләрен язгы санитар чистарту һәм төзекләндерү эшләрен координацияләүне тәкъдим итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендә кабул ителгән б-392 нче номерлы боерыгына теркәлеп килүче кушымталар нигезендә: 1 нче форма буенча ике айлык үткәрү эшләре барышы турындагы мәгълүматны атна саен, чәршәмбе, 2 нче санлы форма буенча 2022 елның 6, 20 апрелендә, 5, 18 һәм 25 маенда Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына җибәрергә.

3.ҖЧҖ “Мехуборка” оешмасына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Каты көнкүреш калдыкларын кабул итү, сортларга аеру һәм күмү буенча эш алып барырга, чүп чыгару өчен махсус машина паркы һәм чүп полигоннарының нәтиҗәле эшен тәэмин итәргә;

4. Мамадыш районында экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитар-эпидемиологик иминлек буенча ведомствоара комиссиягә Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы Мамадыш районы һәм Мамадыш шәһәре буенча территориаль идарәсенә (Маснавиева М.Х.), Мамадыш шәһәре һәм районның авыл җирлекләре территориясендә сәнәгать һәм көнкүреш калдыклары белән эш итүне җайга салу өлкәсендә контрольне көчәйтергә тәкъдим итәргә.

5. Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (С.Н.Ханова) ике айлык кысаларында үткәрелә торган эшне “Нократ” (“Вятка”) газетасында киң күләмдә яктыртып торуны тәэмин итәргә.

6. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлегенең җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә секторына өч эш көне эчендә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль районының www.mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.М.Дәрҗеманов